| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЫСОКОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**Отдел образования**<br>422700, пос.ж/д ст. Высокая Гора,<br>ул. Школьная , 17<br>тел. (8-265)2-36-06, факс (8-265)2-36-00, | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>**Мәгариф бүлеге**<br>422700, Биектау тимер юл станциясе поселогы,<br>Мәктәп урамы, 17<br>тел. (8-265)2-36-06, факс (8-265)2-36-00 |
|---|---|---|

№ 161

16.03.2022

**Белем бирү оешмалары җитәкчеләренә**

“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына
татар телле ата-аналар өчен конференция үткәрү турында

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 1 нче номерлы Биектау гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Татар гаиләсе” Бөтенроссия иҗтимагый фонды белән **“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына** татар телле ата-аналар өчен конференция (алга таба - конференция) үткәрә.

Гаризаларны һәм эшләрне кабул итү – Salima-yunusova@mail.ru адресына 2022 нче елның 1 нче апреленә кадәр дәвам итә.

Белешмәләр өчен телефоннар: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенең милли эшләр буенча методисты Юнысова Сәлимә Фәндүс кызы (884365 2 36 02).

Кушымта: нигезләмә 2 биттә 1 нөсхәдә.

Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары –
“ТР Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының мәгариф бүлеге”
муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.К.Әхмәтҗанов

Кушымта

**“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына татар телле ата-аналар өчен конференциянең нигезләмәсе**

## I. Гомуми мәгълүмат

“Татар гаиләсе” Бөтенроссия иҗтимагый фонды, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 1нче номерлы Биектау гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе **“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына татар телле ата-аналар өчен конференция** (алга таба - конференция) үткәрә.

## Максат һәм бурычлар

- балаларда гаиләгә, әти-әниләргә карата хөрмәт хисен арттыру,

- бала тәрбияләүдә гаиләнең роле зур икәнен күрсәтү, балалар күзлегеннән караганда хәзерге гаиләнең нинди икәнлеген ачыклау;

- талантлы укучыларны барлау;

- әти-әниләр, укытучылар арасында туган телне, йолаларны, гореф-гадәтләрне, рухи кыйммәтләрне, ничек саклап калу турында фикер алышу.

## Катнашу тәртибе

Юнәлешләр:

1. **“Татар милли бизәкле кул эшләнмәләре”** (5-11 нче сыйныф укучылары арасында кул эшләнмәләре бәйгесе).

2. **“Гаиләм — ныклы терәгем, таянычым”** (8-11 нче сыйныф укучылары арасында иншалар бәйгесе).

3. **“Иң зур мирас бер генә: газиз туган тел генә”** (татар телле әти-әниләр арасында балаларга туган телдә тәрбия бирү турында язмалар).

4. **“Мәктәп һәм тәрбияле киләчәк (гаилә һәм мәктәп бергәлеге)”** (укытучылар арасында дәрестән тыш чаралар сценарийлары, гаиләләр белән эш тәҗрибәсе турында язмалар).

Конференция ике этапта үткәрелә.

1нче этап – читтән торып катнашу этабы.

2 нче этап – төп этап.

**Читтән торып катнашу этабы** – гаризаларны һәм эшләрне кабул итү – 2022 нче елның 1 нче апреленә кадәр Salima-yunusova@mail.ru адресына. Эшләр татар телендә кабул ителә. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң нәтиҗәләр ясала, икенче турда катнашучылар исемлеге билгеләнә.

**Төп этап.** Эшләре иң кызыклы, эчтәлекле дип табылган катнашучылар 27 нче апрель көнне сәгать 9.00 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 1 нче номерлы Биектау гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенә **“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына татар телле ата-аналар өчен конференциягә** чакырыла.

**Белешмәләр өчен адрес һәм телефоннар:**

Конференция турында төп мәгълүмат һәм яңалыклар «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 1 нче номерлы Биектау гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең рәсми сайты аша җиткереләчәк.

Белешмәләр өчен телефоннар: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенең милли эшләр буенча методисты Юнысова Сәлимә Фәндүс кызы (884365 2 36 02).

**“Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый” темасына конференциядә катнашу өчен гариза**

| Юнәлеш | Эшнең темасы | Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулы килеш татар телендә) | Оешманың тулы исеме (устав буенча татар телендә) | Сыйныфы | Җитәкчесе | Элемтә өчен телефон | Электрон почта |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |